РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2018 Буа шәһәре № 148/ИК-п

Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районы чикләрендә
муниципаль ихтыяҗлар өчен авыл
хуҗалыгы билгеләнешендәге җир
кишәрлегенең бер өлешен алу турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 11, 49, 56.2-56.11 статьялары, Р Ф Гражданнар кодексының 279-282 статьялары, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 44 статьясы, территорияне планлаштыру һәм межалау проектлары нигезендә, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 16:14:0000000:154 кадастр номерлы 71230268,71 кв.м мәйданлы, Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы, Кыят авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, җир категориясе: авыл хуҗалыгы билгеләнешендә булган, авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен арендаланган җир кишәрлеге мәйданын киметү юлы белән, 10 900,00 кв. м мәйданлы җир кишәрлеге, су башнясы урнаштыру (төзү) өчен алырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән арендатордан алыну Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турындагы килешү нигезендә (якларның ике як ризалыгы буенча яки суд тәртибендә) җир кишәрлеген тиешенчә киметү белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның күчермәсен билгеләнгән тәртиптә алына торган объектның арендаторына, теркәү органына җибәрергә, шулай ук Буа районының «Знамя» газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча, Буа муниципаль районының рәсми сайтында: http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Карар имзаланган көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Буа муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе А.Ф. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Р. Камартдинов